**«Татар әдипләре балаларга»**

Китап – белем чишмәсе, ди халык мәкале. Балалар китабы киләчәк буынны тәрбияләүдә, тормышта дөрес юнәлеш сайлауда зур ярдәмче булып тора. Китап укып үскән баланың күңеле чиста, уйлау сәләте югары дәрәҗәдә була. Алмаз Гыймадиевның «Селфи таягы» китабы урта яшьтәге мәктәп балалары өчен. Бу гыйбрәтле хикәяләрдә бүгенге балалар, яшүсмерләр тормышы сурәтләнгән. Фоат Садриевның «Тургай» китабы үсмерләргә дә , олыларга да тәкъдим ителә. Бу китапны укып балачактагы борчуларын онытып бетергән олылар – балалар тормышының катлаулы яклары, ә балалар – зурларның серләре белән таныша алачак. Тургай кушаматлы малай - ул шук та , кирәк вакытта җитди дә, сер дә саклый белә. Дусларын үз артыннан ияртерлек көчкә ия, тирә яктагыларны сокландыра да. Герой –шагыйрь Муса Җәлилнең «Беренче дәрес» китабы кече яшьтәге мәктәп балалары өчен, монда авторның төрле темаларга багышланган шигырьләре, балладалары урын алган. Китап матур рәсемнәр белән бизәлгән, рәссамы Булат Гыйльванов. Рафис Корбанның «Тимерле чәй», Рифат Сәлахның «Чәчәк яраткан песи» исемле берсеннән – берсе матур, күңелле шигырьләр китабы мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына менә дигән күчтәнәч. Рәшит Бәшәрнең «Качышлы уйный тургай» китабында балалар өчен шигырьләр һәм табышмаклар тупланган. Шагыйрь үзенең нәни дусларын серләр тулы шигъърият иленә кунакка дәшә. Ул илдә сихри төсләр балкышы да, тылсымлы авазлар яңгырашы да , сурәтле хәрәкәт тә – һәммәсе дә бар. Абдулла Алишның мавыктыргыч та , гыйбрәтле дә булган әсәрләрен туплаган «Әкиятләр» китабы мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп балалары өчен тәкъдим ителә. Китап нәниләр өчен укырлык эре хәрефләр белән басылган , рәссам Миләүшә Вәзиева тарафыннан матур рәсемнәр белән бизәлеп эшләнгән. Яңа гына хәреф өйрәнүче мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен Фәйрүзә Мөслимованың «Татарча әлифба» китабы хәрефләрне истә калдырырга, әлифбаны күңелле итеп өйрәнергә ярдәм итәр. Каты тышлыкта, матур рәсемнәр белән бизәп эшләнгән Зәкия Туфайлованың «Әни сүзе», Шәүкәт Галиевның «Светофорның өч сүзе», Әнәс Кариның «Беренче адымнар», Әминә Бикчәнтәеванның «Йокла инде курчагым» китабы мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен . Балаларның кече яшьтән туган телен яратып, үз милләтенең матур әдәбиятын белеп үсүе өчен ,челтерәп аккан чишмә кебек йөгерек телле, мавыктыргыч, дөньяны – табигатьне балаларча күзәтеп язылган җыйнак әсәрләр кирәк. Язучы Фаил Шәфигуллинның «Акбай белән Карабай» китабында тупланган хикәяләр нәкъ шундыйлар.

Балалар әдәбияты нигездә — яхшылык, хаклык һәм матурлык төшенчәләрен яктырта. Татар балалар әдәбияты бөтенкешелек кыйммәтләрен үзендә саклый. Әлеге кыйммәтләр исә балалар аңын кешелекле итү, кечкенә шәхесне тормыш юлын дөрес сайларга өйрәтү өчен тудырылган. Балалар китабы безнең өчен игелекле дус, яхшы киңәшче, якын сердәш ул.

Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы балалар китапханәсе – 3 нче филиал китапханәчесе Гатауллина Нажия Аксән кызы.